Республика Татарстан
**СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Комсомола, д. 4а, с. Старый Кашир, 423357.
Телефон: (85559) 4-86-36,
E-mail: Sksr.sar@.tatar.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КЭШЕР АВЫ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Комсомол урамы, 4а йорт,Иске Кэ авылы, 423357.
Телефон: (85559) 4-86-36,
E-mail: Sksr.sar@.tatar.ru

ОКПО 93068309 ОГРН 1021601312215 ИНН/КПП 1636001259/163601001

КАРАР

2018 елның 24 сентябре № 19 Иске Кәшер авылы

**Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Иске Кәшер авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварында кабул ителгән карары нигезендә № 16» референдум үткәрү инициативасы турында", Иске Кәшер авыл җирлеге Советы хәл итә:

1. 2018 елнын 18 ноябрендә Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2019 елда Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

1). Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:
- Иске Кәшер, Яхшыбай авылларында Сабантуй; Иске Кәшер, Анак, Баткак, Урта Кәшер, Яхшыбай, яшьләр; Петров көне, Баткак авылында Яңа ел, Иске Кәшер, Урта Кәшер, Яхшыбай, Баткак авылларында Өлкәннәр көне;;
- фотоаппарат, проектор сатып алу;
- Урта Кәшер авыл клубы өчен бильярд сатып алу.

2).Җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган

күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту), шул исәптән:
- Иске Кәшер авыл җирлегенең торак пунктында светодиод яктырткычлар урнаштыру;
- Урта Кәшер авыл клубы территориясен киртәләп алу һәм төзелеш материаллары сатып алу ; ;
- МТЗ-82 тракторын тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу;
- авыл җирлегендәге торак пунктлардагы юлларны кышкы чорда Иске Кәшер, Урта Кәшер, Анак, Баткак, Яхшыбай, яшләр авылларында кардан чистарту.
- җәйге чорда Иске Кәшер авыл җирлеге т.п. үлән чабу.

3).Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру, шул исәптән:
- Яхшыбай т. п. зиратында төзелеш материаллары сатып алу ,
Иске Кәшер авыл җирлеге зиратлары өчен инвентарьлар;
- Иске Кәшер авыл җирлеге зиратлары өчен аншлаглар сатып алу;;
- «Сарман»район газетасына некрологлар бирү.

«ӘЙЕ,»ЮК".

3.Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Иске Кәшер авыл жирлеге башлыгы : Р. Н. Дәүләтҗанов